Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XXX-5**

Балык Бистәсе штп. 2022 елның 30 декабре

Татарстан Республикасы «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгатьчелек фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2018 елның 4 сентябрендәге XXXIII-2 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгатьчелек фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2018 елның 4 сентябрендәге XXXIII-2 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 06.10.2020 ел II-2, 01.12.2022 ел XXVIII-3 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 мадданең 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. гавами тыңлаулар уздыру вакытын һәм урынын күрсәтеп, гавами тыңлауларны билгеләү турында мәгълүмат, шулай ук гавами тыңлауларга чыгарыла торган муниципаль норматив хокукый акт проекты гавами тыңлаулар үткәрү көненә кадәр 10 календарь көннән дә соңга калмыйча мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә), шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән кагыйдәләр нигезендә «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба - Бердәм портал) урнаштырылырга тиеш.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында яшәүчеләргә хәбәр итү максатларында гавами тыңлаулар һәм муниципаль норматив хокукый акт

проектын билгеләү турында Бердәм порталда мәгълүмат урнаштыру Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының вәкаләтле хезмәткәре тарафыннан Бердәм порталның кире элемтә платформасының (алга таба-органның шәхси кабинеты) тиешле бүлегендә әлеге пунктның беренче абзацында билгеләнгән срокта шәхси кабинетны кулланып гамәлгә ашырыла.»;

6 маддәне түбәндәге эчтәлектәге 3 өлеш белән тулыландырырга:

«3. Гавами тыңлауларда катнашучылар муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча үзләренең искәртүләрен һәм тәкъдимнәрен Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән кагыйдәләр нигезендә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша җибәрергә хокуклы.

Муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча фикер алышуга чыгарылган искәртүләр һәм тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында яшәүчеләр тарафыннан федераль дәүләт мәгълүмат системасын кулланып, авторизациядән соң анда «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен электрон формада кулланыла торган мәгълүмати системаларның мәгълүмати-технологик бәйләнешен тәэмин итүче инфраструктурада идентификацияләүнең һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып Бердәм порталны кулланып кертелә».

Искәртүләр һәм тәкъдимнәр кертү гавами тыңлаулар билгеләү турындагы мәгълүматны һәм гавами тыңлауларга чыгарылган муниципаль норматив хокукый акт проектын бастырып чыгару көненнән башлана һәм гавами тыңлаулар үткәрү көненә кадәр 2 эш көненнән дә соңга калмыйча төгәлләнә.

Муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр керткәндә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында яшәүчеләр шулай ук үзенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), гражданның шәхесен раслаучы төп документның реквизитлары, туган көне һәм яшәү урыны буенча теркәлү адресы турында мәгълүматны җибәрәләр.

Искәртүләр һәм тәкъдимнәр органның шәхси кабинетына җибәрелә.»;

7 маддәнең 8 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Гавами тыңлауларның нәтиҗәләре турындагы бәяләмәгә оештыру комитеты рәисе һәм сәркатибе имза сала. Кабул ителгән карарларны дәлилләүне дә кертеп, гавами тыңлауларның нәтиҗәләре Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында да да гавами тыңлаулар уздырган көннән алып 3 эш көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарыла (халыкка җиткерелә)».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктураны үстерү буенча урынбасары Д.Н.Ризаевка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы Р.Р. Ислямов